# КАРАР

**12 ноябрь 2021 ел** **№1**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Түбән Арбаш авылы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, сход 12 ноябрь 2021 елда утте.:

"Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Түбән Арбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Совет урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю), проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелек;
- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)
- территорияне кышкы чорда кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)
- Түбән Арбаш авылында артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу;
- Совет урамы, Түбән Арбаш авылы (2 скважина)буенча артезиан скважиналарыннан файдалануга лицензия алу өчен документлар пакетын һәм лаборатория тикшеренүләре әзерләү чараларын тормышка ашыру . ;
- Түбән Арбаш авылы Совет урамында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Түбән Арбаш авылында энергияне саклый торган лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру

« БЕЗ РИЗА» « БЕЗ КАРШЫ»»

Халык җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 71 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 37 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде::

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашучы 37 кеше тавыш бирде;

«юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Түбән Арбаш авылы халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга

2. Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Түбән Арбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә расларга булганнар:

- территорияне кышкы чорда кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

- Түбән Арбаш авылында видеокүзәтү камераларын сатып алу һәм урнаштыру (техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, сатып алу, урнаштыру, карап тоту, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

- Түбән Арбаш авылында энергияне саклый торган лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру;

- кирәкле материал алу һәм булган чишмәне ремонтлау (килешү буенча сатып алу, урнаштыру, карап тоту, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру);;

- Совет урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, ком җәю, вак таш җәю), проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелек;

- карарны кабул ителгән итеп санарга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Өркеш авыл җирлеге башлыгы: А.Ш.Әгъләмова